# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
# КАРАР

№1 10 ноябрь 2025 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге
Яңа Мокшино авылында гражданнарның үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советы 05.11.2019 ел №105 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карарына таянып Аксубай муниципаль районы "Иске Үзи авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАРы:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Яңа Мокшино авылы, Ленин урамы, 20 йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәге бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юлындагы чокырларны ремонтлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).
2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән

инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту җайланмасы (светодиодлы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

РИЗА КАРШЫ

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районы «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова